**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2797**
**30.05.2019**

«Яшьләр көне» шәһәр бәйрәмен үткәрү көнендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында

Яр Чаллы шәһәрендә «Яшьләр көне» шәһәр бәйрәме үткәрелү уңаеннан, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль законның 30 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ санлы Законының 27 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 нче карары белән расланган Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе, шәһәр Уставының 41 маддәсе 9 пунктының 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 29 июнендә 15.00 сәгатьтән 22.10 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә:

1) Хәсән Туфан проспекты буенча ике юнәлештә дә Чулман проспектыннан Раскольников урамына кадәр автомобиль юлы участогында;

2) Раскольников урамы буенча Рәис Беляев проспекты белән кисешкән урынга кадәр.

2. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең ЮХИДИ бүлегенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка җиткерергә һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә әлеге карарны, «Интернет» челтәрендә ведомствоның рәсми сайтында урнаштыру өчен, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев